
Исәнмесез, минем
нәни дуслар!
Хуш килдегез,
рәхим итегез!
Кулга тотып
белем
ачкычларын,
Я, әйдәгез ,
түрдән үтегез!



# ПОРТФЕЛЕҢНЕ ДӨРЕС ҖЫЙ




















# “УКЫП БЕЛ” ТУКТАЛЫШЫ

Габдулла Тукай – татар халкының сөекле шагыйре. Тукайның әкиятләрен ,мәсәлләрен балалар яратып укый. Тукай шигырьләре сине эшчән , тырыш , акыллы , гадел , ярдәмчел , куркусыз булырга өйрәтә,туган телне яратырга өнди.



Муса Җәлил  - татар халкының бөек улы , каһарман шагыйрь. Ул  Бөек  Ватан сугышында катнашып , фашистлар әсирлегендә һәлак була.Немец тоткынлыгында язган шигырьләрен  “ Моабит дәфтәрләре “ дип йөртәләр.




Шәүкәт Галиев – балар өчен бик күп шаян шигырьләр иҗат иткән шагыйрь. Ул уйлап чыгарган Шәвәли исемле малай – синең тиңдәшең. Ул шаярырга, уйнарга, тәмле ашарга ярата.



# ШАЯН ШӘВӘЛИ ТУКТАЛЫШЫ








0 1 2 3 4 5 6 7 8 9 10 11 12 13 14 15


ШКОЛА

Абдулла Алиш – күренекле балалар язучысы.
Ул синең кебек малайлар һәм кызлар өчен берсеннән-берсе кызыклы ,мавыктыргыч һәм гыйбрәтле әкиятләр язган.
Ул да Җәлил кебек фашистлар әсирлегендә Һәлак була.



Роберт Миңнуллин – балаларның яраткан шагыйре.
Ул язган шигырьләр кызык та, шаян да, күңелле дә.Аның шигырьләренә бик күп җырлар язылган.



# “УЙЛАП КАРА” ТУКТАЛЫШЫ







Фәнис Яруллин – күпләргә үрнәк булырдай язучы.
Ул яшь чагында турниктан егылып төшә һәм йөри алмас була.
Шундый авырлыкларга да карамастан ,ул иҗатын дәвам итә.
Фәнис Яруллинның шигырьләре дуслык кадере , туган җирне
ярату турында.





Язучыларның әсәрләрен укып ,син үзең дә сүзнең матурлыгына соклана белү сәләтен ачарсың, әйләнә – тирә дөньяның гүзәллеген күрергә өйрәнерсең. Сиңа укуыңда уңышлар телим! Тугры дусларың изге күңелле укытучыларың һәм сине яратучы әти-әниең һәрвакыт янәшәңдә булсын , ә мәктәп якты киләчәгеңә юл салсын!

Түбән Кама муниципаль районы башлыгы,

**А.Р.Метшин**.